**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 21 июнь № 424

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика мөлкәт казнасы» дәүләт бюджет учреждениесен оештыру турында» 2011 ел, 26 июль, 597 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика мөлкәт казнасы» дәүләт бюджет учреждениесен оештыру турында» 2011 ел, 26 июль, 597 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы мөлкәтен реализацияләү һәм аренда шартнамәләре, түләүсез файдалану шартнамәләре, мөлкәт белән ышанычлы идарә итү шартнамәләре, Татарстан Республикасы мөлкәтенә карата ия булу һәм (яки) файдалану хокукы күчүне күздә тоткан бүтән шартнамәләр төзү хокукына конкурслар (аукционнар) үткәрүне оештыруны;»;

дүртенче абзацка түбәндәге сүзләрне өстәргә «, җаваплы саклау шартнамәсе буенча, шулай ук оператив идарә итү хокукында»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрне куллану турында» 2002 елның 24 июлендәге 101-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә мәҗбүри алынган авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җир кишәрлекләрен гамәлгә кертү буенча ачык сатулар үткәрүне оештыруны».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков